**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Лаеш районының Каип авылы;

Мөслим районының Иске Смыловка авылы;

Спас районының Әҗмәр авылы;

Теләче районының Шәдке авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Аксубай районының Кече Сөнчәле авылындагы Гагарин урамы;

Биектау районының Алат спирт заводы авылындагы Урман урамы;

Биектау районының Әлдермеш авылындагы Яшел урам;

Биектау районының Бөреле җәнлек совхозы поселогындагы Сугышчы-интернационалистлар урамы;

Биектау районының Олы Солабаш авылындагы Октябрь урамы;

Казан шәһәренең Зур Дербышки торак массивындагы Яңа урам;

Кукмара районының Мәмәшир авылындагы Киров урамы;

Минзәлә районының Иске Маҗын авылындагы Тынычлык урамы;

Яңа Чишмә районының Ленино авылындагы Үзәк урам;

Питрәч районының Пимәр авылындагы Совет урамы;

Балык Бистәсе районының Шомарбаш авылындагы Совет урамы;

Спас районының Тукай авылындагы Тукай урамы;

Питрәч районы Белкино авылы янындагы «Ак Барс Питрәч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 8 апрелендәге ПУ-376 номерлы Указының 1 пункты «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче – сигезенче, унынчы абзацлары;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 9 апрелендәге ПУ-380 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 09 июнь
№ ПУ-544